ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.11.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2208**

Зеленодольск муниципаль районының «Ледокол» спорт мәктәбе муниципаль автоном учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм 2020 елның 05 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау буенча комиссия карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Ледокол» спорт мәктәбе МАУ күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны кушымта нигезендә расларга

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 ноябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы «Ледокол» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 3274 номерлы карары;

2.2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау өлешендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2018 елның 23 апрелендәге 959 номерлы карарының 3 пункты.

3. Әлеге карарны ЗМР Советы аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
18.11.2020 № 2208

## «Ледокол» спорт мәктәбе муниципаль автоном учреждениесе

## Түләүле хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге

### Тимераякта массакүләм шуу

| Килүчеләр категориясе | Зурлар | 14 яшькә кадәр балалар |
|---|---|---|
| Тимераякта шуу (1 сәг.) | 100,00 | 70,00 |
| Тимераякларны прокатка алу (1 сәг.) | 50,00 | 50,00 |

| Килүчеләр категориясе | Массакүләм шуугa йөрү өчен абонемент * | | |
|---|---|---|---|
| | Зурлар | 14 яшькә кадәр балалар | Студентлар һәм күп балалы гаиләләр |
| Бәясе бер сәгать исәбеннән 4 тапкыр килгән өчен | 380,00 | 260,00 | 360,00 |
| Бәясе бер сәгать исәбеннән, прокатка тимераяк алып, 4 тапкыр килгән өчен | 580,00 | 460,00 | 560,00 |
| Бәясе бер сәгать исәбеннән 12 тапкыр килгән өчен | 1100,00 | 750,00 | 1000,00 |
| Бәясе бер сәгать исәбеннән, прокатка тимераяк алып, 12 тапкыр килгән өчен | 1700,00 | 1300,00 | 1650,00 |

| Килүчеләр категориясе | Массакүләм шуу өчен лимитсыз абонемент * | | |
|---|---|---|---|
| | Зурлар | 14 яшькә кадәр балалар | Студентлар һәм күп балалы гаиләләр |
| Бәясе 3 айга | 2560,00 | 1790,00 | 2430,00 |
| Бәясе, прокатка тимераяк алып, 3 айга | 3910,00 | 3140,00 | 3780,00 |
| Бәясе 6 айга | 5130,00 | 3590,00 | 4860,00 |
| Бәясе, прокатка тимераяк алып, 6 айга | 7830,00 | 6290,00 | 7560,00 |

| Хезмәт күрсәтү исеме | Бәясе-сум. (төркемнән 1 сәг.) |
|---|---|
| Мини футбол кыры тәкъдим итү (яктыртылмаган һәм киенү-чишенү бүлмәләресез) | 600,00 |
| Мини футбол кыры тәкъдим итү (яктыртылган) | 1000,00 |
| Мини футбол кыры тәкъдим итү (яктыртылган, киенү-чишенү һәм душ белән) | 1500,00 |

| Хезмәт күрсәтү исеме | Чоры | 1 кеше өчен түләү |
|---|---|---|
| Инструктор белән физкультура-сәламәтләндерү төркеме | айга | 800,00 |
| Фигуралы шуу буенча төркем | айга | 700,00 |
| Хоккей буенча төркем | айга | 600,00 |

## Корпоратив клиентлар

| Хезмәтнең исеме | 1 сәгать өчен түләү |
|---|---|
| Бозны арендалау 14.00 сәг. кадәр | 3500,00 |
| Бозны арендалау 14.00 сәг.соң | 5000,00 |
| Бозны арендалау 21.00 сәгатьтән | 3500,00 |

## Тимераякны кайрау

| Хезмәтнең исеме | Түләү |
|---|---|
| Яңа тимераяклар (бер пар тимераяк) | 150,00 |
| Кабат кайрау(бер пар тимераяк) | 100,00 |
| Боз катыргыч машиналары өчен пычак кайрау | 1500 дән 4000,00 гә кадәр |

Абонементлар, Боз сарае расписаниесе нигезендә , массакүләм шуу вакытында гамәлдә.

«Ледокол» СМ МАУ директоры, Гамәлгә куючы белән килешенеп, вакытлы акцияләр үткәрелгәндә, прейскурантның барлык позицияләренә ташламалар билгеләргә хокуклы.